Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
«Лашман авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
гражданнары җыены

**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге
составына керүче Лашман торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

25 октябрь 2024 ел. № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең Лашман торак пунктында халык җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең Лашман торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операцияләрдә булган затлардан, Әфганстанда һәм Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш.

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле

материаллар сатып алу, КРН-2,1Б ротор чапкычын урам кырыйларын чабу өчен Лашман торак пунктында халыкның күпләп ялы өчен шартлар тудыру һәм җәмәгать урыннарын төзекләндерүне оештыру;

**- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү** (Лашман торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булган геройларга мемориаль такта яңарту);

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Лашман торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Лашман торак пунктында җирле әһәмияттәге урам юлларын чокырларга ремонтлау, ясалма тигезсезлекләр төзү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу).

2. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Лашман авылы, Совет ур., 55, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенең рәсми интернет-сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче

Лашман авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Фәттахов